ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 14.12.2016 Казань ш. № 10-44/кс

«Торак-коммуналь хуҗалыгының иң мөһиме идарәсе» акционерлык җәмгыяте өчен салкын суны һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында

“Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәплән чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында” тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын суны һәм ташландык суларны транспортировкалауга башкаручы «Торак-коммуналь хуҗалыгының иң мөһиме идарәсе» акционерлык җәмгыять өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларны билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә билгеләргә

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар басылып чыккан көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Торак-коммуналь хуҗалыгының иң мөһиме идарәсе» акционерлык җәмгыятенә салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешмаларына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт
комитетының 14.12.2016 № 10-44/кс
карарына кушымта

Календарь чорларына салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы «Торак-коммуналь хуҗалыгының иң мөһиме идарәсе» акционерлык җәмгыяте өчен салкын суны һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне бакшкаручы оешманың атамасы | салкын суны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | ташландык суларны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | басылып чыккан көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | басылып чыккан көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр |
| | Муниципаль берәмлек Казан шәһәре | | | | | | |
| 1 | «Торак-коммуналь хуҗалыгының иң мөһиме идарәсе» акционерлык җәмгыяте (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | | | | | | |
| 1.1 | Яшел Үзән шәһәре кулланучылары | 4,67 | 4,67 | 4,67 | 6,08 | 6,08 | 6,08 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге